МИНИСТЕРСТВО ИНФОРМАТИЗАЦИИ И СВЯЗИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.03.2018 Казан ш. № 8-07-пк/3

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының 2016 елның 17 мартындагы ПК-6 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга карата таләпләр үтәлеше буенча комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәш турында законнар үтәлешен тикшереп торуны көчәйтү максатларында Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 19 сентябрендәге 431 номерлы указы, Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы указы кабул ителүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының 2016 елның 17 мартындагы ПК-6 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга карата таләпләр үтәлеше буенча комиссиясе турында нигезләмәгә, түбәндәге эчтәлекле 3.6.1 пунктын өстәп, үзгәреш кертергә:

«3.6.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.2, 3.4, 3.5 пунктларында каралган дәлилле бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрләмәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) гарызнамәләр нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм мәнфәгатьле оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яисә хәбәрләмәләрне беренчел карау нәтиҗәләре буенча дәлилле нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.16, 3.19, 3.22 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка төрле карарны кабул итү өчен киңәшләр.».

Министр вазыйфаларын
үтәүче В.Вандюков